**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**
Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 25. 10. 2019

**КАРАР** ПР-237

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан, кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген актуальләштерү турында

Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күп була торган урыннар исемлеген "Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортларын раслау турында" 25 март, 2015 ел, № 272 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары таләпләренә туры китерү, шулай ук әлеге исемлектән объектларны (территорияләрне) төшереп калдыру, хокукка ия булган федераль башкарма хакимият органнары яки аларның эшчәнлеге өлкәсенә караган, паспортлаштыру Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары белән расланган башка норматив-актлар нигезендә гамәлгә ашырыла торган, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан, кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Ведомствога караган башкарма хакимиятнең федераль органнары яки әлеге объектлар үз эшчәнлекләре өлкәсенә караган, паспортлары Россия Федерациясе законнарында каралган башка норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла торган объектларның хокукка ия булган җитәкчеләренә кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү, категорияләү мәсьәләләре буенча хокук саклау һәм күзәтчелек органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга, шулай ук мондый объектларның куркынычсызлык паспортларын рәсмиләштерергә һәм норматив таләпләр һәм федераль законнар нигезендә аларның террорчылыкка каршы якланыуын көчәйтү буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан, кешеләр күпләп була торган урыннар исемлеген төгәлләштерү турында" 2018 елның 9 ноябрендәге ПР - 274 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева

Сәрвәров И. Х.
3-44-08

Актаныш муниципальрайоны
Башкарма комитеты җитәкче
карарына
25. 10. 2019 № ПР-237
1 нче санлы кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан, кешеләр күпләп җыела торган урыннар исемлеге

| № т/б | Урнашу урыны | Оешма атамасы: |
|---|---|---|
| 1. | 423740, ТР, Актаныш районы, Актаныш авылы, Юбилей ур. | "Яшьлек" мәдәни-күңел ачу үзәге каршындагы мәйдан |
| 2. | 423740, ТР, Актаныш районы, Актаныш авылы, Тынычлык пр. | “Актаныш басмалары " буасы янындагы сквер |